РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.02.2026 № 24/бк/к

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә күрсәтелә торган мунча хезмәтләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә һәм санитар-эпидемиологик иминлекне һәм халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтүне оештыру максатында Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында халыкка мунча хезмәтләре билгеләнгән тәртиптә эшләүче мунча хуҗалыгы оешмалары тарафыннан бирелә күрсәтелә дип билгеләргә.

2. Юыну һәм сауна бәясен 1 сәгать дәвамлылыгында 300 сум күләмендә билгеләргә.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләренә карата юынуга һәм саунага 1 сәгать дәвамлылыгында, атнага 1 тапкыр вакыт аралыгында түбәндәге ташламалы бәяләрне билгеләргә:

- Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, тыл хезмәтчәннәре, сугышчан хәрәкәт инвалидлары, махсус хәрби операция инвалидлары, I төркем инвалидлар, 7 яшькә кадәрге балалар-бушлай;
- барлык пенсионерлар да "Өлкәннәр көнендә" (һәр елның 1 октябреннән 10 октябренә кадәр) - 1 көн бушлай;
- инвалидлар декадасында 1-3 группа инвалидлар (һәр елның 1 декабреннән 10 декабренә кадәр) - 1 көн бушлай;
- 2 һәм 3 төркем инвалидлар, 7-18 яшьлек күп балалы гаиләләрдәге балалар - 150 сум;
- пенсионерлар, хезмәт ветераннары – 200 сум;
- сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, шулай ук аларның гаилә әгъзалары – 250 сум.

Ташламалар мунча комплексына ташламалы йөрү хокукын раслый торган тиешле документ күрсәтелгәндә бирелә.

Әгәр граждан ташламаны ике яисә аннан күбрәк нигездә алырга хокуклы булса, ташлама хезмәт күрсәтүнең бәясе иң түбән (яисә түләүсез) булган нигездә бирелә.

4. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында күрсәтелә торган мунча хезмәтләре турында» 2023 елның 17 мартындагы 65 Бк/к номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карар имза салынган көннән законлы көченә керә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов